**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ XXVIII СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р №110**

с. Муслюмово «28» августа 2018 года

**Мөслим муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы 187 номерлы «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы Регламенты турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Мөслим районы прокурорының 2018 елның 26 июлендәге 02-08-01-2018 номерлы протестын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Мөслим муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы 187 номерлы «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы Регламенты турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы Регламентының 24 статьясын яңа редакциядә бәян итәргә:

«24 статья. Район Советы карарларының үз көченә керүе һәм басылып чыгуы

1. Район Советы тарафыннан кабул ителгән карарлар район Советы башлыгына - Рәисенә кул кую һәм халыкка җиткерү өчен җибәрелә. Карарга кушымта район Башлыгы урынбасары - район Советы Рәисе урынбасары яки район Советы аппараты җитәкчесе тарафыннан имзалана.

2. Район Советы карарлары, әгәр законнарда, район уставында, әлеге Регламентта башкасы каралмаган булса, аларга кул куйган көннән үз көченә керә.

3. Процедура мәсьәләләре буенча карарлар кабул ителгәннән бирле үз көченә керә.

4. Район Советының салымнар һәм җыемнар турындагы карарлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

5. Район бюджеты турындагы карарлар Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы карарлар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

7. Рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) карарлары район Советы аша гамәлгә ашырыла:

- хокукый акт текстын район җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган массакүләм мәгълүмат чараларында яки район территориясендә таратыла торган бүтән массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару . Хокукый акт текстын башка массакүләм мәгълүмат чараларында бастырганда әлеге басылуның рәсми булуы турында билге булырга тиеш;

- хокукый акт текстын яки хокукый акт проектын районның рәсми сайтында

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»на урнаштыру.

Муниципаль хокукый актны бастырганда (халыкка җиткергәндә) массакүләм мәгълүмат чарасының чыгу датасы күрсәтелергә тиеш.

8. Район Советы карарлары муниципаль хокукый актларның бердәм реестрына кертелергә тиеш.»

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы
Мөслим муниципаль районы Советы
рәисе урынбасары А. М. Әхмәтҗанов